**27 ноябрь**

**«Калач» әкиятен сәхнәләштерү**

Икенче кечкенәләр төркем балалары өчен би-ба-бо курчаклары ярдәмендә «Калач» татар халык әкияте күрсәтелде. Балалар бик рәхәтләнеп һәм игътибар белән карадылар, тыңладылар. Аннары балаларга театрның кечкенә актерлары булырга тәкъдим ителде, балалар үзләренә ошаган курчакларны сайлап алып, иптәшләренә курчак театры күрсәттеләр.

